СИШӘМБЕ
6 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 30 (5830)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат кузәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

РАЙОН МАТБУГАТЫ ҺӘМ ПРОПАГАНДА

ВКП(б) Үзәк Комитетының 1938 нче ел, 14 нче ноябрь карарында матбугат турында болай диелә: „Марксизм-ленинизм пропагандасында хәл иткеч төп корал—матбугат: журналлар, газеталар, брошюралар булырга тиеш, ә телдән пропаганда алып бару булышчы, ярдәмче урынны тотарга тиеш. Матбугат теге яки бу хакикәтне шунда ук барлык кешеләргә җиткерүгә мөмкинлек бирә, шуңа күрә дә ул телдән пропаганда алып баруга караганда көчлерәк“. ВКП(б) Үзәк Комитетының бу карары чыкканнан соң үткән вакыт эчендә большевистик матбугат кадрларыбызны, партияле һәм партиясез большевикларны марксизм-ленинизм теориясе белән коралландыру эшендә гаят зур чараларның берсе булды.

Моны безнең республикабыздагы өлкә матбугаты мисалендә дә бик ачык күрергә була. Үткән елны безнең өлкә газеталарыбыз ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләргә ярдәмгә күп кенә консультацияләр, теоретик мәкаләләр һәм сорауларга җаваплар басып чыгардылар. „Красная Татария“ 97, „Кызыл Татарстан“ 85, „Хӗрлӗ Йалав“ 60, „Комсомолец Татарии“ 41, „Яш Сталинчы“ 47, „Татарстан Большевигы“ журналы 18 мәкалә һәм консультация басып чыгардылар. Болардан тыш, газета битләрендә лекторларның, пропагандистларның, парткабинетларның эшләрен яктырткан, марксизм-ленинизм теориясен үзлегеннән өйрәнүнең уңышлы тәҗрибәләрен күрсәткән мәкаләләр, хәбәрләр системалы рәвештә урнаштырылып киленәләр.

Аерым районнарда, предприятиеләрдә партия пропагандасының куелышы турында, тәҗрибәләрне уртаклашу киңәшмәләре, теоретик беседалар турында яктырту эшен газеталар сизелерлек рәвештә яхшырттылар. Газеталар пропаганда мәсьәләләренә карата системалы рәвештә баш мәкаләләр биреп киләләр.

Марксизм-ленинизм пропагандасын оештыру, аның сыйфатын күтәрү эшендә шактый үрнәк күрсәткән район газеталары да юк түгел. Мисаль өчен ВКП(б) ның Калинин райкомы органы „Сталин юлыннан“ газетасын алырга була. Бу газета үзенең битләрендә районда пропаганда эшенең торышын системалы рәвештә яктырта, партия тарихын үзлекләреннән өйрәнүче аерым иптәшләрнең тәҗрибәләре, түгәрәкләрнең эшләре турында, парткабинетларның, пропагандистларның эшләре турында еш кына мәкаләләр, хәбәрләр урнаштыра. Калинин районында пропаганда эшләренең шактый яхшы куелуында район газетасының роле, һич шиксез, зур.

Ләкин бу әле марксизм-ленинизм пропагандасын яктыртуда матбугатның кимчелекләре юк дигән сүз түгел. ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләргә ярдәмгә теоретик мәкаләләрне, консультацияләрне, лекцияләрне тагын да ешрак урнаштыруда, бигрәк тә аларның сыйфатларын яхшыртуда, уңышлы тәҗрибәләрне яктырту һәм газета укучыларның сорауларына кәнәгатләнерлек җаваплар бирүдә матбугатның бик күп эшлисе бар әле.

Республикабызда чыга торган күп кенә район газеталарында пропаганда мәсьәләләрен яктырту эше әле һаман да тиешле югарылыкка куелмаган. Болар рәтенә — „Күмәк хуҗалык“ (Мөслим районы), „Кызыл Зәй“ (Заинский районы), „Колхоз“ (Баулы районы), „Трактор“ (Тымытык районы), „Сталин Юлы“ (Алабуга районы), „Колхоз ударнигы“ (Актаныш районы), „Коммуна“ (Азнакай районы), „Большевистик колхоз“ (Кызыл Йолдыз районы) газеталарын кертергә була. Бу газеталар пропаганда мәсьәләләре турында бик аз язалар, язганда да мәсьәләнең эчтәлегенә аз тукталалар, күп вакыт бик өстән генә, информация төсендә генә, яисә коры статистика белән генә канәгатләнеп калалар. Марксизм-ленинизм теориясен үзләштерү эшендәге уңышлы тәҗрибәләрне киң яктырту, булган кимчелекләрне үз вактында ачып салу һәм аларны бетерүгә партия оешмаларының игтибарын юнәлдерү практикасы бик йомшак. Бу газеталарда пропаганда мәсьәләләренә карата баш мәкаләләр бөтенләй диярлек булмый.

Пропаганда мәсьәләләре буенча газетага язу өчен материаллар күп, тематика гаят бай. Һәрбер районда парткабинет бар, боларның эшләре турында информация, коры статистика төсендә генә язмыйча, бәлки аларның эшләрен тулы яктыртырга кирәк. Парткабинетлар тарафыннан үткәрелә торган индивидуаль һәм групповой консультацияләрнең эчтәлекләре турында, ВКП(б) тарихын үзлегеннән өйрәнүчеләргә парткабинет тарафыннан нинди булышлыклар күрсәтелүе турында язарга кирәк. Лекцияләрнең сыйфаты һәм эчтәлеге турында яктыртуга зур игтибар бирелергә тиеш.

Марксизм-ленинизм теориясен үзлегеннән өйрәнүдә аерым иптәшләрнең бай тәҗрибәләрен, эш методларын тулысынча һәм системалы рәвештә яктыртып барырга кирәк. Түгәрәк занятиеләренең ничек үтүен, занятиеләрнең эчтәлеген, пропагандист һәм түгәрәк членнарының занятиегә ничек хәзерләнеп килүләрен яктыртырга кирәк. Моның өчен редакция работниклары үзләре пропаганда мәсьәләләре белән таныш булырга, бу эшне оештыра белергә, марксизм-ленинизм теориясен үзләштерүдә үзләре башкаларга үрнәк күрсәтергә тиешләр.

Белоруссиядә, Курский һәм Орловский өлкәләрендә марксизм-ленинизм пропагандасының куелышы турында ВКП(б) Үзәк Комитетының 1938 нче ел, 16 нчы август карарында болай диелә: „Өлкә һәм район газеталары пропаганданы оештыру тәҗрибәсен яктыртып кына калмаска, бәлки лекцияләрнең, консультацияләрнең һәм түгәрәк занятиеләренең сыйфатына һәм эчтәлегенә дә бәя бирергә тиешләр“.

Барлык район газеталары үзләренең эшләрен ВКП(б) Үзәк Комитеты күрсәтмәләре нигезендә үзгәртеп корырга, газета битләрендә пропаганда мәсьәләләрен яктырту эшендә кискен борылыш ясарга тиешләр.

ВКП(б) ның район комитетлары газета редакцияләренең эшенә көндәлек җитәкчелекне һәм контрольне көчәйтергә, аларга практик ярдәм күрсәтергә тиешләр.

ССР Союзы белән Литва арасында чик билгеләү буенча катнаш үзәк комиссиянең Литва делегациясе Москвага килде

СССР белән Литва арасында чик билгеләү буенча катнаш үзәк комиссиясенең Литва делегациясе 4 нче февральдә Москвага килде. Делегация составында делегациянең председателе Сакалаускас әфәнде һәм делегация членнары Кришунас, Новицкис һәм Лесис әфәнделәр бар. Килүчеләрне Белоруссия вокзалында: СССР белән Литва арасында чик билгеләү буенча катнаш үзәк комиссиянең совет делегациясе председателе иптәш Л. М. Куроптев, совет делегациясе членнары А. А. Смирнов һәм П. В. Теплов иптәшләр, шулай ук Литва ышанычлысы Багдонас әфәнде җитәкчелегендә Литваның Москвадагы миссиясе составы каршыладылар. (ТАСС).

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

4 нче февральдә фронтта башлыча разведчикларның эзләнүләре булды. Ладога күленнән төньяктагы районда пехота частьләренең сугышлары башланып китте.

Безнең авиация разведка очышлары һәм хәрби очышлар үткәрде.

РӘСЕМДӘ: Советлар Союзы герое, батальон комиссары иптәш Д. А. Балаханов. (ТАСС фото-клишесе).

Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгы алдыннан

КУРСАНТЛАР ЯҢА ЙӨКЛӘМӘЛӘР АЛДЫЛАР

Казан аэроклубы коллективы, данлыклы юбилейгә хәзерлек уңае белән, укуда яхшы күрсәткечләр бирү, шулай ук мәктәптә оборона эшләрен көчәйтү турында йөкләмәләр алды.

Курсантлардан зур бер группа „Ворошиловча атучы“ значогына нормалар тапшыруга хәзерләнә. Алар хәзер тренировкалар үтәләр.

23 нче февральдә аэроклубта бәйрәм кичәсе булачак. Кичәдә доклад һәм үзешчәнлек сәнгате түгәрәкләренең чыгышлары була.

ДОПРИЗЫВНИКЛАР ПОХОДЫ

Кайбыч районында Кызыл Армиянең 22 еллыгына хәзерлек башланды. Район парткабинеты гражданнар сугышы тарихына, Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенә һәм Хәрби Диңгез Флотына багышланган күргәзмә оештырды.

Районның һәрбер авылында колхозчыларның җыелышлары үткәреләчәк һәм аларда Кызыл Армиянең 22 еллыгы турында докладлар тыңланачак. Райком 68 докладчы билгеләде инде.

Осоавиахимның район советы, район клубында хәрби почмак оештырды. 20 нче февральдә допризывниклардан 30 кеше чаңгы походына чыгачаклар. Ату ярышлары үткәреләчәк. Бу ярышларга 4 команда катнаша. Иске Тебәрдә, Кайбыч һәм башка авыллардагы урта мәктәпләрдә дә ату һәм чаңгыда йөрү ярышлары, „ГСО“-„ПВХО“ һәм „Ворошиловча атучы“ значокларына массовый күләмдә норма тапшырулар үткәреләчәк. (Тат. ТАСС).

КЫЗЫЛ АРМИЯ ЙОРТЫНДА

2 нче февральдә Кызыл Армия Йортында частьләрдәге клуб начальникларының киңәшмәсе үткәрелде. Анда еллыкка хәзерләнү һәм аны үткәрү мәсьәләсе тикшерелде.

9 нчы февральдә беседачылар һәм докладчылар өчен „Кызыл Армия—социализм иленең какшамас терәге“ дигән темада махсус инструктаж үткәреләчәк.

Кызыл Армия йортының драмтүгәрәге Кызыл Армиянең Көнбатыш Белоруссияне коткару өчен булган героик көрәшен күрсәтә торган пьесаны хәзерли.

23 нче февральдә Кызыл Армия Йортының Колонналы залында зур концерт, 25 нче февральдә Кызыл Армия сугышчыларының һәм начальникларының сәнгат работниклары белән очрашу кичәсе булачак.

Казан театрларының артистлары хәрби частьләр өчен күп кенә постановкалар куячаклар. Татарстан кинофикация тресты Кызыл Армия сугышчыларына хезмәт күрсәтү өчен махсус киносеанслар оештыра.

КАЗАН ЮРИДИК ИНСТИТУТЫНДА ОБОРОНА ЭШЕ

Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының 22 еллыгына багышлап, Казан юридик институтында 7 нче февральдән 20 нче февральгә кадәр ату ярышлары үткәрелә. Хәзер институтта „Ворошиловча атучы“ значогы алган 138 кеше бар. Норма тапшырган иптәшләр арасында фәнни работниклар да күп. Доцентлардан Юсупов һәм Попов, аспирант Степанова иптәшләр „Ворошиловча атучы“ значогының II нче баскычына норма тапшырдылар.

3 нче февральдә чаңгычы студентлар противогазлар киеп Югары Ослан районының Ключище авылына киттеләр. Алар анда Кызыл Армия турында һәм авылда хәрби-физкультура эшенең бурычлары турында беседалар үткәрәчәкләр. Студенткалардан 40 кеше медицина сестралары хәзерләү курсларында укый.

Хәрби кабинет янында станковый пулеметны өйрәнү түгәрәге төзелде.

Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең еллыгына карата институтта оборона мәсьәләләре буенча лекцияләр укылачак, институтның физкультура һәм оборона эше активистларын бүләкләү булачак.

ҮЗӘК КӨТЕПХАНӘДӘ КҮРГӘЗМӘ

Казанның В. И. Ленин исемендәге Үзәк Көтепханәсе Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең һәм Хәрби Диңгез Флотының данлыклы XXII еллыгына багышлап зур күргәзмә оештыра. Күргәзмә „Ленин—Сталин һәм Кызыл Армия“, „Кызыл Армия хезмәт ияләрен азат итүче“ дигән ике зур бүлектән гыйбарәт булачак. Анда Ленин—Сталин иптәшләрнең Кызыл Армияне оештырудагы рольләре, Кызыл Армия тарафыннан үтелгән данлыклы тарихи юл, Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия халыкларын азат итү турында һәм ак финнәргә каршы Кызыл Армиянең героик көрәш алып баруы турында күрсәткән күп төрле материаллар куела.

Библиография бүлеге Кызыл Армия турында чыккан әдәбияттан такдим исемлекләре төзеде һәм бу исемлекләр шәһәр көтепханәләренә җибәрелде.

Көтепханәдә булган әдәбияттан уку залында Кызыл Армия турында китап витринасы төзелде. Витринада политик әдәбият белән бер рәттән, батыр Кызыл Армия турында художество әдәбияты да куелды. Шундыйлардан Фурмановның „Чапаев“, Всеволод Ивановның „Пархоменко“ дигән әсәрләре һәм башка әсәрләр бар. Шулай ук „Хәрби һава һөҗүменнән сакланырга хәзер бул“ дигән витрина да оештырылды.

ВКП(б) Үзәк Комитеты— *И. В. Сталинга*
СССР Совнаркомы— *В. М. Молотовка*

Кадерле Иосиф Виссарионович һәм Вячеслав Михайлович!

Бүген безнең барыбызның да шатлыклы көн. Безнең зур бәхетебез турында сөйләү өчен сүзләр җитми. Котып морякларының кечкенә хезмәтләренә Ватан югары бәя бирде. Иосиф Виссарионович һәм Вячеслав Михайлович, Сезгә рәхмәт, Сезгә тирән күңелебездән рәхмәт белдерәбез.

Без бу бүләкнең нинди бөек икәнлеген аңлыйбыз, Сталин тарафыннан тәрбияләнүчеләр һәм социалистик Ватан патриотлары дигән югары исемне изге рәвештә йөртергә ант итәбез. Сталинча батыр, Сталинча скромный булырга, армый-талмый эшләргә, нык рәвештә өйрәнергә ант итәбез.

Без, седовчылар, үзебезнең көчләребезне һәм, әгәр дә кирәк булса тормышыбызны да кызганмыйча, партия һәм иптәш Сталин җибәргән һәр урында Ватан файдасына эшләрбез.

Безнең байрак — Сталин. Без шушы байрак астында яшәдек, бозлар арасында хәрәкәт иткән көннәрне шушы байрак астында стихия белән көрәш алып бардык. Бу байрак белән без барлык кыенлыкларны җиңдек, бу байрак астында без киләчәктә дә җиңәрбез.

Ленин орденлы „Георгий Седов“ бозваткыч пароходының экипажы:

К. Бадигин	В. Буйницкий	Н. Шарыпов
С. Токарев	Н. Бекасов	А. Ефремов
И. Недзвецкий	А. Соболевский	Е. Гаманков
И. Гетман	Д. Трофимов	А. Полянский
Д. Буторин	В. Алферов	П. Мегер.

4/II 40 ел.

Кремль, ВКП(б) Үзәк Комитеты— *иптәш СТАЛИНГА*
ССР Союзы Совнаркомы— *иптәш МОЛОТОВКА*

Кадерле Иосиф Виссарионович!
Кадерле Вячеслав Михайлович!

Партия һәм хөкүмәт, мине икенче „Алтын Йолдыз“ медале белән бүләкләп, миңа гаят зур ышаныч күрсәттеләр. Иосиф Виссарионович, Вячеслав Михайлович, йөрәгемдә Сезгә чын күңелдән рәхмәт хисе һәм кайнар мәхәббәт хисе тулы.

Сталин заданиесен үтәү — ул, Совет патриоты өчен иң зур бәхет. Совет кешеләре партиянең һәм халыкның теләген үтәгән вакытта, аларны бер нинди киртәләр дә туктата алмый.

Бөек Сталин һәм Ватан, Совет халкының батыр унбиш улын бозлар арасындагы пленлектән чыгару өчен, безне котып төненә һәм Гренландия бозлары арасына җибәрделәр. Безнең карабның бортына юлбашчының исеме язылган, бу исем безне рухландырды. „И. Сталин“ бозваткычының моряклары йөрәкләрендә Сталин исеме булган хәлдә, стихиягә карамастан, үзләренә тапшырылган эшнең уңышлы булуына нык ышанып, алга бардылар.

Большевиклар партиясе һәм иптәш Сталин котыпчыларда батырлык, ныклык, җиңүләргә булган тайпылмас теләк, теләсә нинди кыенлыкларны җиңә белү сыйфатларын тәрбияләделәр. Совет халкы котыпчыларны ярата һәм алар турында кайгыртучанлык күрсәтә. Бу бөек ышанычны һәм мәхәббәтне данлыклы яңа эшләр белән акларбыз.

Туганнарым Иосиф Виссарионович һәм Вячеслав Михайлович, чын күңелемнән тагын бер тапкыр рәхмәт! Сезне ышандырам: партия эше өчен, Ленин — Сталин эше өчен көрәшкә үземнең бөтен гомеремне, бөтен көчләремне бирермен.

ИВАН ПАПАНИН.
Советлар Союзы Герое.

4/II 40- ел.

„И. СТАЛИН“ БОЗВАТКЫЧЫ, 4/II 40 ЕЛ.

МОСКВА, КРЕМЛЬ.

СТАЛИН һәм МОЛОТОВ иптәшләргә

Арктика флоты флагманы „Иосиф Сталин“ бозваткычының экипажы, Сезнең заданиегезне үтәү буенча чираттагы рейста чагында, СССР Верховный Советы Президиумы указы буенча бозваткычның Ленин ордены белән, карабның иң яхшы кешеләренең Советлар Союзы орденнары һәм медальләре белән бүләкләнүе турында, бозваткычның капитаны иптәш Белоусовка Советлар Союзы Герое исме бирелү турында ишетеп гаят дәрәҗәдә шатланды.

Зур игтибар һәм кайгыртучанлык өчен без партиягә, хөкүмәткә һәм Сезнең үзегезгә, Сталин һәм Молотов иптәшләр, рәхмәт белдерәбез. Безнең экипаж киләчәктә дә куәтле социалистик Ватаныбыз файдасына һәм аның даны өчен үз-үзен аямыйча һәм чын күңелдән эшләячәгенә Сезгә сүз бирә. Ватаныбызның беренче чакыруы белән үк без һәрбер минутта аны якларга һәм сакларга хәзер торабыз. Большевиклар партиясе җитәкчелеге һәм иптәш Сталин булганда без җиңелмәбез.

Яшәсен куәтле социалистик Ватаныбыз!

Яшәсен дөньядагы иң зирәк Совет Хөкүмәтенең башлыгы Вячеслав Михайлович Молотов!

Яшәсен социализм иленең барлык җиңүләрен рухландыручы һәм оештыручы кадерлебез һәм сөеклебез Иосиф Виссарионович СТАЛИН!

„Иосиф Сталин“ бозваткычы экипажының тапшыруы буенча:
Капитан М. БЕЛОУСОВ.
Помполит хезмәтләрен үтәүче С. СТЕПАНОВ.

ЧИТ ИЛ ЭШЛӘРЕ ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫНДА

3 нче февральдә Эстония илчесе Рей әфәнде Чит Ил Эшләре Халык Комиссары урынбасары иптәш В. П. Потемкин янында булды һәм аңа нота тапшырды. Нотада Таллин шәһәре гаванында торучы Совет хәрби караблары тарафыннан 2 нче февральдә Эстония самолетына ату вакыйгасе белдерелә. Югарыда күрсәтелгән фактта Эстония республикасы территориясенең кагылгысызлыгы бозылган дип карап, Эстония хөкүмәте үзенең Москвадагы илчесенә шул уңай белән нота аша протест белдерүне тапшырган.

4 нче февральдә иптәш Потемкин Рей әфәндегә Чит Ил Эшләре Халык Комиссариатының җавап нотасын тапшырды. Бу нотада Совет хәрби караблары тарафыннан Эстония самолетына югарыда күрсәтелгән ату турында аңлатма бирелә. Кызыл байраклы Балтик флотының белдерүенә караганда, Эстония самолетлары Таллин порты һәм анда торучы Совет хәрби караблары өстендә очмаячаклар, дип Эстония командованиесе белән килешү булуына да карамастан, 2 нче февральдә Таллинда Эстония самолеты булып чыккан „Бристоль Бульдог“ типындагы самолет үз маршрутыннан читкә чыккан һәм Совет хәрби караблары өстеннән берничә тапкыр очып үткән. Совет хәрби караблары, аны чит ил самолеты дип уйлап, зенит артиллериясеннән аңа берничә тапкыр атканнар.

Бу хәлдә аңлашылмаучылык урын алганлыгын күрсәтеп, Совет хөкүмәте бу уңай белән тәэссеф белдерде.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

КОЛХОЗ АКТИВЫ БЕЛӘН ЭШЛӘҮ

Кызыл Йолдыз районында колхоз активын политик тәрбияләү эшенең куелышы турында ВКП(б) Өлкә Комитеты карарыннан соң районда колхоз активын тәрбияләү эше яхшыра башлады. Кыска гына вакыт эчендә колхоз активы арасында шактый эшләр башкарылды.

Колхоз активы өчен районда 20 урында политграмота түгәрәкләре оештырылды һәм алар квалификацияле җитәкчеләр белән ныгытылдылар. Бу түгәрәкләрдә кырчылык бригадалары бригадирлары, авыл советы һәм колхоз правлениесе председательләре, ферма мөдирләре, агротехниклар һәм завхозлар, колхоз производствосының башка җаваплы урыннарында эшләүче активистлар укыйлар.

Югары Сон авылында бу эш бигрәк тә яхшы куелган. Монда колхоз активистларының саны 77 кешегә җитә. Шулардан 45 кеше кичке мәктәптә һәм политграмота түгәрәгендә укый, калганнары партия тарихын үзлекләреннән һәм түгәрәкләрдә өйрәнәләр. Бу авылда колхоз активы өчен әледән-әле популяр лекцияләр һәм докладлар үткәрелә. Соңгы вакытларда дингә каршы пропаганда мәсьәләләре буенча 3 лекция укылды, халыкара хәл һәм политик мәсьәләләр буенча 35 доклад куелды һәм беседа үткәрелде.

Дингә каршы пропаганда мәсьәләләре буенча соңгы көннәрдә районда 29 урында лекцияләр укылды, аларны 3 меңгә якын кеше тыңлады. Халыкара хәл мәсьәләләре буенча да лекцияләр һәм докладлар үткәрелә. Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларга хәзерлек кампаниясе барышында агитаторларның яңа кадрлары үсеп чыктылар.

Бу агитаторлар сайлаулар үткәч тә үзләренә тапшырылган эшне зур тырышлык белән дәвам иттерәләр.

Ләкин уңышлар белән генә тынычланып калмаска, сайлаулар вактында ирешелгән уңышларны арттыру өчен агитаторлар кадрларына большевистик җитәкчелек итү һәм агитация-масса эшен тагын да киңрәк җәелдерү өчен бөтен мөмкинлекләрдән файдаланырга кирәк.

Сәйфеттинов.

ВКП(б) ның Кызыл Йолдыз райкомының пропаганда-агитация бүлеге мөдире.

ВКП(б) райкомнарының пленумнарында

САБА РАЙОНЫ

28—29 нчы январьда ВКП(б) ның Саба райкомы пленумы булды. Пленумда ВКП(б) Өлкә Комитетының VIII нче пленумы йомгаклары тикшерелде.

1939 нчы елда ВКП(б) ның Саба райкомы тарафыннан партия сафларына 274 кеше кабул ителде. Шулардан ВКП(б) членнары 98 һәм кандидатлар 176 кеше. 1939 нчы елда 11 колхозда партиянең башлангыч оешмасы һәм 9 колхозда кандидатлар группасы оештырылды.

ВКП(б) сафларына кабул итү эшендә күп кенә кимчелекләр дә бар әле. Сатыш авылы башлангыч партоешмасында (секретаре иптәш Шәймәрдәнев) кайбер кешеләрне ныклап тикшермичә партиягә кабул итү фактларына юл куелган.

Рекомендация бирүгә кайбер коммунистлар җавапсыз карыйлар. Практик эштә сыналмаган, җәмагат эшенә актив катнашмаган һәм социаль чыгышын яшергән кешеләргә рекомендацияләр бирү фактлары район башкарма комитеты һәм Сатыш авылы партоешмаларында урын алган. Кайбер башлангыч партоешмаларда ВКП(б) га яңа кабул ителгәннәр белән эшләүгә җитәрлек игтибар бирелми. Мартен һәм Пүкәл авылларындагы башлангыч партоешмаларда яшь коммунистларны тәрбияләү эше аеруча начар тора.

Пленумда докладлар буенча сөйләүче иптәшләр партиянең район оешмасы эшендәге җитешсезлекләрне нык тәнкыйть иттеләр һәм практик тәкъдимнәр керттеләр. Пленум тикшерелгән мәсьәләләр буенча конкрет карар кабул итте.

И. Гарипов.

ТӘТЕШ РАЙОНЫ

ВКП(б) ның Тәтеш райкомы пленумы булып үтте.

1939 нчы елда партиянең Тәтеш районы оешмасында 131 кеше партиягә кабул ителгән. Шулай да әле районда партиягә яңа членнар кабул итү эше канәгатьләнерлек алып барылмый. „Союзмука“, редакция, дәүләт банкысы, автоколонна һәм леспромхоз партоешмалары ел буена партиягә бер кеше дә кабул итмәгәннәр.

Бу мәсьәлә буенча 14 кеше сөйләде. Алар партоешма эшендәге күп кенә кимчелекләрне күрсәттеләр.

Пленум шулай ук, 1940 нчы елның язгы чәчүенә хәзерлек турында район советы башкарма комитеты председателенең урынбасары иптәш Кратковның докладын тыңлады. Ул 1940 нчы елның язгы чәчүенә хәзерлекнең гафу ителмәслек начар баруын күрсәтеп үтте. Авыл хуҗалыгы инвентарена ремонт ясау бик акрын бара. Тәтеш МТС ындагы 60 тракторның 24 нә генә ремонт ясалган. Чәчү орлыклары туплау һаман да тәгалләнмәгән. Кышкы агротехника чаралары да канәгатьләнерлек үткәрелми.

Райком пленумы һәр ике мәсьәлә буенча кабул иткән резолюцияләрендә Өлкә Комитеты пленумы карарларын яхшы дип тапканлыгын күрсәтте һәм аларны тормышка ашыру өчен практик чаралар билгеләде.

Г. Ганиев.

АГИТАЦИЯ ЭШЕН ЙОМШАРТМАСКА

Арча районында хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулардан соң, кайбер урыннарда агитация-масса эшен туктату кебек фактлар күренә башлады. Мәсәлән, Штерә авылында масса арасында бер төрле дә аңлату эше алып барылмый. Агитколлектив җитәкчесе агитаторларга җитәкчелек итми. Партиянең башлангыч оешмасы секретаре иптәш Сабирова да агитация эшен яхшырту, сайлаулар вактында ирешелгән уңышлы нәтиҗәләрне ныгыту белән кызыксынмый. Төбәк Чокырча һәм Чулпан авылларында да агитколлективлар (җитәкчеләре Федорова һәм Степанов иптәшләр) сайлаулар үтү белән үк агитация эшен туктаттылар.

Районда 22 клуб, 23 уку өе, күп кенә санда көтепханә һәм кызыл почмаклар бар. Сайлаулар вактында алар яхшы гына эшләделәр. Ләкин хәзер алар да эшләрен йомшарттылар. Мәсәлән, Батыр Курса авылындагы уку өендә (мөдире иптәш Хәлилова) кычкырып укулар һәм беседа үткәрүләр соңгы вакытларда бөтенләй үткәрелми башлады. Сикертән, Казиле һәм Зур Бирәзә авылларындагы уку өйләрендә дә шундый ук күренеш.

Агитация-масса эшләре өзлексез алып барылырга тиеш.

Шири Җәлал.

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНДА

ВКП(б) Өлкә Комитеты Бюросы карары белән ВКП(б) сафыннан чыгарылдылар:

Тимофеев М. Г.—хезмәт дисциплинасын бозганлыгы һәм эчүчелеге өчен.

Булкин Н. Н.—партия һәм хезмәт дисциплинасын бозганлыгы һәм эчүчелеге өчен.

Карташев А. М.—эчеп-исереп партия билетын югалтканлыгы өчен.

Павлов П. А.—ВКП(б) уставын һәм хезмәт дисциплинасын тупас рәвештә бозганлыгы өчен.

Җәләлеттинов Б. З.—ВКП(б) сафына очраклы рәвештә килеп кергән кеше.

Подшивалов А. Ф.—ВКП(б) членлыгына кандидатлык карточкасын исерек хәлдә югалтканлыгы өчен.

Закирова Б. З.—ВКП(б) уставын тупас рәвештә бозганлыгы өчен.

Шанин Н. П.—исерек хәлдә партбилетын югалтканлыгы өчен.

Лихачев П. А.—коммунистларны бер партоешмадан икенче оешмага күчерү турында ВКП(б) Үзәк Комитетының инструкциясен бозуы һәм партиягә членлык взносларын түләмәгәнлеге өчен.

Зәйнуллин Х. З.—ВКП(б) га, аерым коммунистларга яла ягуы һәм урынсызга судлашып йөрүе өчен.

Журавлев Н. А.—3 елга иректән мәхрүм ителгәнлеге өчен.

Кузнецов Г. Т.—ВКП(б) членлыгына кандидат дигән бөек исемне аклый алмаганлыгы өчен.

Модестов А. А.—ВКП(б) уставын тупас рәвештә бозганлыгы өчен.

Юридический институт студенты А. Б. Хлебников һәм Мединститут студенткасы К. А. Акимова иптәшләр Сталин районы Г. Тукай исемендәге балалар көтепханәсендә „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнү өстендә.
И. Галиев фотосы.

ТАССР-ның XX еллыгына хәзерлек

ДАНЛЫКЛЫ ЮБИЛЕЙ ХӨРМӘТЕНӘ

Киез итек-фетр фабрикасының отделка цехы коллективы мехчылар чакыруына кушылып, үз өстенә конкрет йөкләмәләр алды. Орденлы Татарстан республикасының данлыклы юбилеен производствода яңа уңышлар белән каршылау өчен көрәш башланды. Барлык бүлекләр, сменалар һәм аерым эшчеләр социалистик ярыш договорларын яңарталар. Цех буенча ярты еллык планны 25 нче июньгә арттырып үтәргә, цехта барлык эшчеләрнең дә стахановча эшләүләренә ирешергә,—ярыш шартлары әнә шундый.

Бу цехның чистарту бүлегендә смена мастеры булып эшләүче иптәш Лобанова:

— Без ярты еллык планны 15 нче июньгә 120 процент итеп үтәү һәм февраль аенда 82 кеше урынына 54 кеше белән дә планны срогыннан элек 120 процент итеп үтәү йөкләмәсен алдык. Һәм үзебез белән тиңләшергә иптәш Шакиров сменасын чакырдык. Без хәзер сменага 3.850 пар урнына, 4.200—4.300 пар итек чистартуга ирештек. Сменада яшь өйрәнчекләрдән 12 кешенең тиздән барсының да стахановча эшләүләренә ирешәчәкбез, ди.

Бу сменаның атаклы стахановчысы иптәш Вафина сменага 55 пар урнына 120—140 пар итек чистартуны көндәлек эштә ныгытты. Февраль ае планын ул 20 нче числога 250 процент һәм ярты еллык планны Татарстанның XX еллык бәйрәме көненә 280 процент итеп үтәү йөкләмәсен алды. Үзе белән бергә эшләүче иптәш Габдрахманованы ярышка чакырды.

Ермолаев сменасында товар кабул итүче иптәш Мельников узган ел айлык планын уртача 150 процент үтәгән булса, быел айлык планын 200 процент итеп үтәү өчен көрәшә. Сменага 350 пар урнына уртача 600 пар итек кабул итә.

Х. Рәхмәтуллина.

ЯҢА УҢЫШЛАР ӨЧЕН

„Спартак“ комбинатында орденлы Татарстан республикасының данлыклы XX еллыгына зур хәзерлек алып барыла. Бу уңай белән комбинатның барлык цехларында һәм бүлекләрендә беседалар үткәрелә.

Комбинатның тарихы төзелә. Бу тарихта, элек ярым кустарьчылык хәлендә булган заводның хәзер комбинат булып әверелүе, продукция җитештерүнең елдан-ел күтәрелә баруы, кадрларның үсеше саннар һәм фактлар белән күрсәтеләчәк.

Комбинат коллективы данлыклы еллыкны истә калдыру, хезмәт җитештерүчәнлегенең тагын да үсүен тәэмин итү өчен конкрет йөкләмәләр алды. 1940 нчы елның беренче ярты ел планын 10 көн элек үтәп, хезмәт җитештерүчәнлеген үткән ел белән чагыштырганда 6 ай эчендә 7 процент үстерергә булды. Отходлардан һәм ярым фабрикатлардан дөрес файдалану белән күн товарларына экономия ясарга һәм шуның белән 1940 нчы елда планнан тыш 30 мең пар аяк киеме эшләп чыгарырга булды. Моның өчен производствоның аерым процессларын үзгәртеп кору чаралары билгеләнде. Комбинатның эшчеләр һәм инженер-техник работниклар коллективы алган йөкләмәләрен уңышлы үтәү өчен Казандагы киез итек-фетр фабрикасы коллективын социалистик ярышка чакырды.

Кисү һәм хәзерләү цехлары коллективының 4 нче февральдә булган гомуми җыелышында мехчылар мөрәҗәгате тикшерелде. Бу цехларның коллективлары мөрәҗәгатне зур күтәренкелек белән каршыладылар һәм республикабызның XX еллыгы уңае белән алган йөкләмәләрен намус белән үтәргә булдылар. Хәзер бу цехларда хезмәт җитештерүчәнлеге көннән-көн үсә. Хәзерләү цехының иптәш Кириллов бригадасы стахановчы вахтага басып бик яхшы нәтиҗәләргә иреште. Бригада планны һәр көн арттырып үти башлады.

К. Халиков.

МЕХЧЫЛАР ЧАКЫРУЫНА КУШЫЛАБЫЗ

Мехкомбинат эшчеләре һәм инженер-техник работниклары коллективының мөрәҗәгате уңае белән Вахитов исемендәге жиркомбинатның барлык заводларында һәм бүлекләрендә митинглар булды.

Митингта катнашучы эшчеләр һәм инженер-техник работниклар орденлы Татарстан республикасының XX еллыгын социалистик төзелешнең барлык тармакларында тагын да зуррак җиңүләр белән каршылау турында мехчыларның чакыруын зур шатлык белән каршы алуларын әйттеләр һәм үзләренең өсләренә конкрет йөкләмәләр алдылар.

Шәм заводы стахановчысы иптәш Бариева болай диде:

— Без мехчыларның бу чакыруына зур шатлык белән кушылабыз һәм һәр вакыттагы кебек үк без бу ярышта да җиңеп чыгучы булырбыз. Үзебезнең орденлы республикабызның XX еллык юбилеен производствода яңа казанышлар белән каршыларбыз.

Шәм цехы коллективы 6 айлык планны 20 нче июньгә, ә еллык планны 5 нче декабрьгә үтәү йөкләмәсен алды.

Таҗиева.

ФИН АК ГВАРДЕЕЦЛАРЫНА КАРШЫ СУГЫШЛАРНЫҢ ГЕРОЕ

СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ КОМИССАР БАЛАХАНОВ

Дмитрий Александрович Балаханов—карт моряк. Ул диңгездә төрле хәлләрне күргән. Салкын канлылык, түземлелек һәм батырлык аңа стихиягә каршы көрәштә җиңүче булып чыгарга булышлык иткән.

Кызыл Армиядә Балаханов омтылышлы, кыю, батыр сугышчы булып әверелә, ул үзендә Сталин типындагы комиссарның большевистик сыйфатларын тәрбияли.

Үзе игтибарлы һәм таләп итүчән булып, бу сыйфатларны ул частьнең командирларында һәм политрукларында да булдырырга тырыша. Кешеләр турында кайгыртуны Балаханов Ворошиловча, Сталинча аңлый.

Кешеләр турында аталарча кайгырту, аларның ихтиаҗларын һәм сорауларын белү—комиссар Балахановның аерымлык сыйфаты.

Кечкенә генә эш тә комиссарның игтибарыннан читтә калмый. Полкның хат ташучысы болай дип сөйли:

— Комиссар мине очрата һәм сорый: „Эшләр ни хәлдә?“ ди. „Ярыйсы“—мин әйтәм. „Юк,—ди комиссар,—ярыйсы түгел, начар“ ди. Мин уйга калдым: „Нәрсә булган икән“—мин әйтәм. Газеталарны, хатларны нак сугыш уты эченә илтеп тапшырам,—тагын нәрсә кирәк икән? Ә комиссар һаман да риза түгел...“. Шунда ул мине өйрәтте. „Сугышчыларга газеталар, хатлар гына түгел, кәгазьләр, конвертлар да ташырга кирәк, аларның өйләренә җибәрәсе хатларын да җыеп китәргә кирәк“ диде. Моны эшләү минем башыма да килмәгән иде.

... К. авылы өчен барган уңышлы сугыштан соң батальоннарның берсе ак финнәрне ун километрдан артык куып барды. Кич белән батальон ялга туктады. Кешеләр тәмам ачыкканнар иде, ә кухняләр дошманны куып баручы гаскәрләр артыннан барып җитә алмадылар.

Комиссар шунда ук юлын тапты: гади өч плитәдә, өч чиләк белән бөтен батальонга җитәрлек аш хәзерләнде. Кухняләр килеп җиткәндә сугышчылар барсы да тук иде инде.

Комиссар сугышчыларның һәрберсен бик яхшы белә. Шундый бер хәл булды. Зур бер пунктны алу өчен ак финнәргә каршы көн ярым сугыш барды. Маннергеймчеләр һәрбер мөмкинлектән файдаланырга тырыштылар. Ләкин комбат Фаустов кулланган хәйләкәр маневр дошманны тар-мар итәргә ярдәм итте: дошманның блиндажлары аларны ясаган ак финнәрнең үзләре өчен каберга әйләнделәр.

Балаханов сугышчыларны котларга килде. Бөтен батальон тезелде.

Комиссар кинәт кенә:

— Ә пулеметчы Новиков кайда?—диде.

Чыннан да, Новиков, бу сугышта яраланып, госпитальгә җибәрелгән иде. Комиссар госпитальгә отделение командирын җибәрергә, Новиковның хәлен сорашырга һәм аңа сәлам әйтергә боерык бирде. Ничек инде: һәр кемне котлыйлар, ә Новиковны онытканнар!

... Пропаганда инструкторы Илларионов ак финнәргә каршы ике тапкыр атакага барды. Соңгысында ул бармаска тиеш иде. Ләкин комиссарның сугышка барырга рөхсәт бирүен бик үтенеп сорады.

Илларионов гайрәт белән, салкын кан белән сугышты. Граната белән дошманның пулемет расчетын юк итте, бу пулеметның позициясен үтеп китте. Ул алга омтылды... Атака бетеп килгәндә генә ак фин снайперының пулясе аны яралады.

Балаханов моны беренче булып күрде. Дошман снайперларының утлары астында ул үзенең иптәшен сугыш кырыннан күтәреп алып чыкты. Яра куркынычлы иде, кичекмәстән госпитальгә озатырга кирәк иде. Ләкин юлны өзлексез агылып торучы артиллерия каплаган иде. Балаханов Илларионовка үзенең атын бирде һәм озата баручыга:

— Хәзер үк врачка алып барырга!—дип боерык бирде.

Балаханов булган иң авыр сугыш Т. авылы өчен сугыш булды.

Сугышка чыгар алдыннан комиссар политрукларны һәм парторгларны җыйды. Ул аларга алда торган бурыч турында, сугышта коммунистның һәм комсомолецның тоткан урны турында сөйләде. Подразделениеләрдә партия җыелышлары үткәрелде. Иң яхшы 28 иптәшне большевиклар сафына кабул иттеләр. Роталарда „сугышчан листоклар“ чыгарылды. Ленин ордены белән бүләкләнгән элемтәче Соловьев үзенең пулеметчы иптәшләрен ярышка чакырды. Пулеметчылар, аның чакыруын кабул итеп, үз чиратларында саперларны чакырдылар. Дошманны тиз тар-мар итү өчен сугышчан ярыш әнә шулай башланды.

Комиссар Балаханов сугышның нак үзәгендә булды. Дошманның көчле пулемет һәм миномет уты астында ике рота җиргә яттылар. Күпер җимерелгән булып чыкты, боз аркылы чыгу мөмкин түгел иде.

Комиссар саперларга күперне төзәтергә приказ бирә. Ул, алар белән бергә эшли. Коммунистлар һәм комсомолецлар, аңардан үрнәк алып, саперларга булышлык итәләр. Дошман уты астында кызу эш кайный.

Күпер төзәтелә. Гадәттә моңа берничә тәүлек кирәк булыр иде, ә монда 4 сәгать эчендә бөтенесе эшләнде.

Ләкин шул арада ак финнәр таралган солдатларын җыярга, сугыш кораллары китерергә өлгерделәр. Дошманның дүрт пулеметы күпердән сул яктагы биеклеккә күчерелде һәм көчле рәвештә ата башлады. Балахановның шинель җиңен ике урыннан пуля тишеп үтте.

Комиссар ротадан ротага үрмәләп барды, сугышчыларны, командирларны, политрукларны кискен атакага хәзерләде.

Икенче эшелонның ике ротасы әйләнеп үтәргә киттеләр. Кинәт урманда моторлар тавышы яңгырады. Алар безнең танклар иде...

Танклар күперне тыныч кына үттеләр һәм дошманның атып тора торган коралларын бастыра башладылар.

— Данлыклы танкистларыбызга һәм саперларыбызга кызыл армеецларча рәхмәт,—дип кычкырды Балаханов.—Ватаныбыз өчен, туганыбыз Сталин өчен, минем арттан, атакага!

Йөзләрчә тавышлар сөекле комиссарның ялкынлы сүзләрен элеп алдылар һәм бердәм булып танклар артыннан киттеләр. Комиссар алда иде. Аның артыннан—йөзләрчә һәм йөзләрчә сугышчылар,—бөтен часть!

Үлгәнгә салышкан бер ак фин бандиты башын күтәрде. Ул, комиссарның үзе янына килеп җитүен көткән булса кирәк. Сапер взводының командиры Сидоренко бандитның маневрын сизде. Ул комиссарга ярдәмгә ашыкты һәм дошманны граната белән үтерде.

Танклар дошманның ут точкаларын бастыруны дәвам иттерделәр. Пехота ак бандитларны штык һәм гранаталар белән тар-мар итте.

Шулай итеп, дошманның ныгытылган пункты алынды. Бу юлы ак финнәр, тизрәк качу өчен, чаңгыларны гына түгел, хәтта аяк киемнәрен дә ташладылар. Алар кар салкыныннан да курыкмадылар. Балаханов һөҗүменнән алар яхшы ук тирләгәннәр, күрәсең!

Ләкин әле сугыш бетмәде. Дошман үзенең резервларын җыйнады һәм оборонадан контратакага күчте. Дошманның артиллериясе безнең команда пункты урнашкан йортны тупка тота башлады.

Дошманның беренче контратакасы уңышсыз чыкты. Ләкин ак финнәр икенче контратакага ташландылар.

Икенче атаканы да кире кайтарып, Балаханов командир белән бергә команда пунктына кайттылар. Дошман снарядлары йортка якын гына төшәләр иде. Шартлаулы пуляләр тәрәзәләрне тишеп үттеләр. Санитарлар группасы белән берлектә комиссар яралыларны беренче этажга күчерде. Алар өчен анда куркынычсызрак иде.

Штаб начальнигы Морозов—ничек кенә булса да Т. авылын алырга—дип яңа гына алынган приказ турында доклад ясый...

Политруклар һәм парторглар җыналалар. Комиссар аларның белдерүләрен игтибар белән тыңлый. Үзе өч минуттан артык сөйләми:

— Тагын бер удар ясау белән без дошманны ныгытылган оялардан кыйнап чыгарырбыз, иптәшләр,—... ә фланглардан әйләнеп үтүче частьләребез аның җанлы көчләрен кыйнап бетерерләр. Батыррак булыгыз!

Атакадан берничә минут элек Балаханов партбюро секретаре Ивашенковны үз янына чакырып алды. Партия оешмасының үсүе турында сөйләштеләр. Сугышлар вактында күп кенә иптәшләр партиягә алынганнар иде.

Яңа алынганнар белән аерым эш алып барырга, һәрберсенә көче җитәрлек эш бирергә, аларны партия тормышына актив катнашуга тартырга кирәк иде.

Беседа бетеп килә иде.

— Әйе, иптәш Ивашенко[illegible] бүген син атакага бармассың, [illegible]де комиссар.

— Ни өчен?

— Чөнки комиссарның приказы шундый, полкка җитәкчеләр кирәк. Аңладыңмы?

Ләкин шулай да Ивашенков атакада катнашырга рөхсәт ала алды. Ул Балаханов артыннан барды. Ул, сугышчыларны мәкерле дошманга атакага чакыручы комиссарның ышанулы тавышын ишетте, — Ватан өчен, сөекле Сталин өчен! Ул, атакага баручыларның алдында, көрәштә куркуны белмәүче, җиңү дигән сүздән башка сүзне белмәүче батыр комиссар барганны күрде!

... Зур каенның сул ягында дошман пулеметы тыкырдады. Балаханов осталык белән граната ташлады, һәм пулемет тынды. Икенче граната фин минометчигына эләкте...

Сугыш бетергә якынлашты. Җиңү безнең якта, героик комиссар Балаханов ягында булды.

Орденлы өлкән политрук

Я. Ватолин.

КАЗАН—ЧИСТАЙ—БӨГЕЛМӘ ТРАКТЫН ТӨЗЕК ҺӘМ КУЛЬТУРАЛЫ ИТИК!

ЙӨКЛӘМӘЛӘРНЕ ҮТИБЕЗ

„13 лет Октября“ артеле колхозчыларының мөраҗәгате Столбище районы хезмәт ияләрендә гаять зур производство активлыгы тудырды. Бу мөраҗәгат юллар төзү өлкәсендә кискен борылыш ясауга көчле этәргеч ясады.

Районның партия, совет һәм комсомол оешмалары юл төзелеше мәсьәләсе белән соңгы вакытларда җиддирәк шөгыльләнә башладылар. „13 лет Октября“ артеле кохозчылары мөраҗәгате актив җыелышларында махсус рәвештә тикшерелү үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли. Бу җыелышларда Чкаловский трактын төзекләндерү өчен конкрет чаралар билгеләнде һәм бу чаралар хәзер практик рәвештә тормышка да ашырыла башлады.

Алдынгылар инициативасы районның барлык колхозлары тарафыннан да зур күтәренкелек белән каршыланды. Һәрбер колхоз үз өстенә конкрет йөкләмәләр ала һәм юл төзү эше буенча дими бригадалар төзи.

„Земледелец“, „20 лет Октября“, „Комсомолец“ колхозлары, М. Горький, В. И. Ленин исемендәге колхозлар һәм дистәләрчә башка колхозлар үзара социалистик ярыш договорлары төзеделәр. Алар юлларны төзеклендерү буенча еллык планны орденлы республикабызның XX еллыгына үтәүне ышандырдылар. Колхозчылар алган йөкләмәләрен үти дә башладылар. Төзү материалларын эш объектларына ташу эшенең соңгы ун көнлектә 10—15 тапкырга артуы алынган йөкләмәләрнең эш белән ныгытылуы турында сөйли. „Земледелец“ һәм В. И. Ленин исемендәге колхозлар төзү материалларын ташуны тәгәлләделәр дә инде. Бу эштә аеруча алдынгылыкны тоткан Ленин исемендәге колхоз председателе Наумов һәм бригадир Артемьев иптәшләр акча белән бүләкләнделәр.

Эш тоткарсыз рәвештә бара. Тарлыши авылына якын булган карьердагы таш байлыгы 75 мең кубометр күләмендә исәпләнә. Ташның сыйфаты да яхшы. Карьерга килгән олауларга таш төяүдә һичбер тоткарлыклар юк. Монда без хәзер ашханә һәм кызыл почмак оештырдык. Юл төзүчеләр өчен биллиард, патефон һәм башка күңел ачу уеннары булдырдык. Һәр көнне кычкырып газета укулар һәм беседалар үткәрәбез.

Безне бу башлангыч адымнар гына һич тынычландырмый. Чөнки эшнең зур күләме һәм хәл иткече алда әле. Масса активлыгына көндәлек һәм оператив җитәкчелек иткән хәлдә, алган йөкләмәләрне тулысынча намус белән үтәү—сугышчан бурыч менә шул. Бу бурычны үтәрбез. Чкаловский трактының безнең районга караган 22 километрын чын-чынлап төзек һәм культуралы юл итүне большевикларча хәл итәрбез. Моның өчен бөтен мөмкинлекләр, бөтен шартлар тудырылган.

Коноплев, Калафатова.

ЧИСТАЙЛЫЛАР, БЕЗНЕҢ ЧАКЫРУНЫ КАБУЛ ИТЕГЕЗ!

Бөгелмә районын орденлы республикабызның башкаласы белән тоташтыручы Чкаловский тракты безнең район аркылы үтә. Соңгы елларда без үз участкыларыбызны төзекләндерү буенча байтак кына эшләр башкардык. Ләкин юлларыбызның гомуми торышы бүгенге көн таләпләренә тулы җавап биреп җиткерми әле. Юлларның бөтен җирдә дә төзек булмавы йөк әйләнеше планын үтәүгә зур тоткарлык ясый. Язгы һәм көзге пычракларда бу хәл аеруча нык сизелә.

Бу хәл якын арада бетерелергә тиеш. Без, Чкаловский трактын төзекләндерү турында Столбище районы колхозчылары инициативасын бердәм рәвештә яклыйбыз һәм төзек, культуралы юллар өчен булган социалистик ярышка зур шатлык белән кушылабыз.

Чкаловский трактының безнең район территориясендә 3 километрын яңадан төзергә һәм 5 километрына капиталь ремонт ясарга кирәк. Моның өчен 3.000 кубометрга якын төзү материаллары ташылачак. Чынлап тотынганда бу безнең өчен бер айлык эш.

Колхозчылар һәм колхоз авылының барлык җәмагатчелеге юлларны төзекләндерүдә алган йөкләмәләрен практик эш белән ныгыталар. ВКП(б) райкомы янында юллар төзелеше буенча махсус комиссия төзелде. Комиссия членнары күптән түгел генә юл трассасын йөреп чыктылар. Һәрбер тармак, участкы буенча конкрет эш планы төзелде. Бу план һәрбер колхозга, һәрбер авыл советына җиткерелде. Төзү материалларын ташу планының үтәлешен тикшерү буенча ныклы контроль булдырылды.

Авыллардагы партия, совет һәм комсомол оешмаларына район активының ярдәмен оештырдык. Район активыннан 26 кеше авылларга җибәрелде. Турыдан-туры алар катнашы белән юл төзелеше планын һич сүзсез үтәү өчен практик чаралар күрелә. Колхозларда даими бригадалар оештырыла. „Восход“ һәм „Большевик“ артеле колхозчылары үзара ярышып эшләгән хәлдә, төзү материалларын ташу эшен 20 нче февральгә тәгәлләү өчен көрәшәләр.

Колхозчылар үз өсләренә алган йөкләмәләрен намус белән үтиләр. Киров исемендәге колхозда оештырылган юл төзү бригадасының эш күрсәткечләре моны ачык рәвештә раслый. Колхозның мактаулы стахановчысы иптәш Фәсхеттинов тарафыннан җитәкчелек ителә торган бригада членнары грави ташу планын системалы рәвештә 180—200 процент итеп үтиләр. „Комбайн“ колхозында юл төзелеше эшен комсомол оешмасы үз инициативасына алды. Бригадага комсорг иптәш Сабитова үзе җитәкчелек итә. „Алга“, „13 лет РККА“, „Ирек“ колхозларында да эш шундый күтәренкелек белән бара. Юл төзелеше объектларына төзү материаллары ташу эшендә бу колхозларның һәр кайсында 30—35 кеше һәм 15—20 ат эшли. Ә гомумән районыбыз күләмендә юл төзелешендә 1 нче февральдән алып һәр көнне 220 ат һәм 320 кеше эшли башлады.

Төзү материалларын эш объектларына ташуны без 23 нче февральгә, данлыклы Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең XXII еллыгына, ә трактны төзекләндерү планын 25 нче июньгә, Татарстан республикасының XX еллык бәйрәменә тәгәлләячәкбез. Бу эштә аеруча үрнәк күрсәткән колхозлар һәм авыл советларының башкарма комитетлары район башкарма комитеты тарафыннан бүләкләнәчәкләр. Үз участкыбызда һәрбер биш километр саен ял итү будкылары, ә Каргалы авылында автомашиналар һәм атлар туктау өчен павильон төзибез.

Күптән түгел генә юл төзү активистларының район киңәшмәсе булып узды. Бу киңәшмәдә без Чкаловский трактын төзү буенча Чистай районын социалистик ярышка чакырдык. Бу ярышта беренчелекне яулап алачагыбызга һич шикләнмибез.

З. Закиров.

Кызыл Армия район советының башкарма комитеты председателе, ТАССР Верховный Советы депутаты.

Рәсемдә: Юл төзү йөкләмәсен үтәгән колхозларның (Столбище районы) комсомол оешмасы секретарьларыннан бер группа. Утырганнар, сулдан: П. Бажанов (Молотов исемендәге колхоз), Г. Гаврилов („Комсомолец“ колхозы), М. Кондратьева (Ворошилов исемендәге колхоз); басып торучылар: Н. Титов („Победитель“ колхозы), А. Вашуров („Красная Заря“ колхозы). Уңда: ВЛКСМ ның Столбище район комитеты секретаре иптәш Н. Байцеров.

Б. Невзоров фотосы,

ҖИДДИ БОРЫЛЫШ КИРӘК

Машина-юл станцияләре юл—төзү работникларының зур мактанычы ул. Алар әле соңгы елларда гына оештырылдылар һәм үзләрен тулысы белән акладылар. Мәсәлән, грейдер машинасы һәм беккер көрәкләре тракторлар ярдәме белән эшләгән хәлдә, юллар төзү эшендә меңнәрчә кешеләрне алмаштыралар. Аларның эш сыйфатлары да югары.

Татарстанда бердән-бер машина-юл станциясе бар. Аның карамагында 12 ЧТЗ тракторы, 11 грейдер машиналары, 28 беккер көрәкләре, 18 автомашина һәм башкалар бар. Бу станция юл төзү участкылары өчен үрнәк булып хезмәт итәргә, юл төзү эшләрен тизләтүдә этәргеч көч булырга тиеш иде.

Кызганычка каршы, станция һич канәгатьләнерлек эшләми. Татарстан Совнаркомы янындагы Юл Төзү Идарәсенең һәм шулай ук станция работникларының гамьсезлекләре, борыла алмаучанлыклары аркасында машина-юл станциясе аяныч хәлгә китерелгән. Нәтиҗәдә, ул 1939 нчы ел планын 39 процентка гына үтәгән.

Юллар төзү эшенең быелгы сезонына да станция чиктән тыш начар хәзерләнә. Механизмнарны ремонтлау буенча төзелгән график үтәлеше ачыктан-ачык өзелә. Мәсәлән, бүгенге көнгә бары тик 6 трактор һәм 3 автомашина гына ремонтланган. Ә грейдер машиналарын һәм беккер көрәкләрен ремонтлау эше бөтенләй башланмаган да әле. „Ремонт эшләрен 25 нче апрельдән дә иртә тәгәлли алмаячакбыз“ ди станция директоры иптәш Теплов. Ә бит юл төзү эшләре 1 нче апрельдән киң колач алырга тиеш.

Станция өчен кадрлар хәзерләү эше үз агымына куелган. Бу эш өчен билгеләнгән акча файдаланылмый ята. Нәтиҗәдә, 18 тракторчы, 16 грейдерчы һәм 20 беккерчы җитешми. Машина-юл станциясенең директоры иптәш Теплов кадрлар хәзерләү эшендә җавапсызлык күрсәтә, булган машиналарны тулы көчләрендә эшләтү чараларын күрми.

Станция алдында торган бурычлар гаять зур һәм җаваплы. Ул Чкаловский һәм Зюрей трактларында катлаулы эшләрне башкару белән бергә, Булдырь нефть разведкасын Чистай шәһәре белән тоташтыручы юлны да тулысынча үз көче белән башкарырга тиеш.

Төзү сезоны башлануга күп калмады. Машина-юл станциясенең бу сезонга тулы хәзерлеген тәэмин итүдә, аны кадрлар белән ныгытуда Юл Төзү Идарәсе ашыгыч чаралар күрергә тиеш.

К. Биков.

ЮЛ ТӨЗҮЧЕЛӘРГӘ БЕЗНЕҢ ЯРДӘМ

Чкаловский трактын төзүдә колхозчылар белән берлектә, барлык хезмәт ияләре, барлык җәмагатчелек катнашырга тиеш. Без, „Факел“ артеле членнары моны аңлыйбыз һәм алдынгы колхозлар инициативасын бердәм рәвештә яклыйбыз.

Юл төзүчеләргә практик ярдәм күрсәтү буенча без түбәндәге чараларны билгеләдек: һәр ял көнне артель членнарының массовый рәвештә юл төзелешенә чыгуларын оештырабыз. Төзү материалларын эш объектларына ташу өчен без 40 ат һәм 30 кеше билгеләдек. Аларны тиешле инструментлар белән тәэмин иттек.

Өстебезгә алган йөкләмәләрне намус белән башкарып чыгарбыз.

П. Сиротин.

Чистай шәһәрендәге „Факел“ артеле правлениесе председателе.

* * *

Халык хуҗалыгының кызу рәвештә үсүе юллар хуҗалыгын тәртипкә китерүне катылык белән куя. Бу таләпне үтәү йөзеннән илебезнең һәм шулай ук республикабызның алдынгы колхозлары Ферганә каналы төзелеше тәҗрибәсен юллар төзү эшенә күчерүне оештырдылар.

Бу кайнар инициативага без дә кушылабыз. Казан—Бөгелмә трактының безнең Чистай районына караган 8,5 километрын өр яңадан төзү һәм 9 километрын ремонтлау эшендә якыннан катнашуны ышандырабыз. Хәзерге көндә төзү материалларын ташу эшенә 2 автомашина һәм 50 кеше билгеләдек. Ә төзү сезоны башлангач бу ярдәмне без 2—3 тапкырга арттырачакбыз. Республикабызның данлыклы XX еллыгын йөкләмәләребезне практик эштә үтәү белән каршылаячакбыз.

М. Абрамов.

Заготзерно управляющие урынбасары.

* * *

Сталин исемендәге Зур Ферганә каналын кыска срокта төзү гаять әһәмиятле һәм тарихи җиңүләребезнең берсе. Ул Үзбәкстан һәм Таҗикстан республикаларының барлык хезмәт ияләре ирке белән, бөек Ленин—Сталин партиясе ирке белән барлыкка китерелде. Бу гүзәл каналны төзүдә тупланган бай тәҗрибә хәзер кыю рәвештә юллар төзелешенә дә күчерелә.

Бу гүзәл башлангычка без, Лесхоз работниклары да, зур күтәренкелек белән кушылдык. Юл төзелешенә 10 ат, 2 автомашина һәм 15 кеше билгеләгән хәлдә, төзү материалларын ташу планын, ә төзү эшләре башлангач, төзү планын арттырып үтәүне йөкләмә итеп алабыз.

Н. Скотников.

Чистай шәһәрендәге Лесхоз директоры.

Казан—Чистай—Бөгелмә трактының картасы.

ЧАКЫРУГА ЭШ БЕЛӘН ҖАВАП БИРӘЛӘР

Чистай районының „Доброволец“ колхозы членнары юл төзелеше планын Татарстан АССР ның 20 еллыгына тулысынча үтәү һәм 28 нче февральгә 500 кубометр төзү материаллары хәзерләү һәм ташып кую буенча конкрет йөкләмәләр алдылар. Моның өчен „Доброволец“ колхозы юл төзелешендә эшләү өчен 42 кеше һәм 18 ат билгеләде. Билгеләнгән кешеләр 29 нчы январьда участкыга грави ташу эшенә керештеләр.

„Доброволец“ колхозы членнары районда юл төзелеше эшендә Ферганә каналын төзүчеләр тәҗрибәсен кулланырга чакрып, Чистай районының барлык колхозларына, колхозчыларына һәм җәмагат оешмаларына мөраҗәгат иттеләр.

ҖАВАПЛЫ ҺӘМ МАКТАУЛЫ БУРЫЧ

Социализм илендә, автомобиль транспорты кызу адымнар белән үскән илдә, юлларны төзекләндерү, аларга реконструкция ясау бүгенге көннең җаваплы һәм мактаулы бурычларыннан берсе. Автомобильләр хәзер халык хуҗалыгының барлык тармакларында да киң кулланыла. Бу исә бездән, юл төзүчеләрдән, культуралы, тоташ автомагистральләр булдыруны катылык белән таләп итә. Һәм без бу таләпне, һич шиксез, үтәргә чакырылган кешеләр.

Партиябез һәм хөкүмәтебез юллар төзелешенә зур игтибар бирәләр. Юл төзелеше кадрлары да бөек Ленин—Сталин партиясенең көндәлек кайгыртучанлык күрсәтүе һәм практик ярдәме белән чолганып алынганнар. Юлларны тиз һәм югары сыйфатлы итеп төзү өчен барлык шартлар тудырылган. Илебезнең алдынгы республикаларында, өлкәләрендә юл төзүчеләр бу кайгыртучанлык күрсәтүгә практик эш белән җавап бирәләр. Мәсәлән, Москва—Минск, Москва—Киев автоюллары күпләр өчен үрнәк булып хезмәт итәләр. Бу юллар илебезнең мактанычы.

Орденлы Татарстан республикасында да юлларны төзекләндерү өлкәсендә соңгы елларда шактый эшләр башкарылды. Патша Россиясендә хөкем сөргән юлсызлыкны бетерүдә җиңүле рәвештә алга барабыз.

Шулай да, без халык хуҗалыгының гомуми үсешеннән артта калабыз әле. Аеруча әһәмиятле урын тоткан Чкаловский, Казан—Алабуга—Минзәлә һәм Уральский трактларының төзеклеге һич канәгатьләнерлек түгел әле.

1940 нчы ел юллар төзелеше өлкәсендә кискен борылыш ясау, автоюллар магистрален үрнәк хәлгә китерү елы булырга тиеш. Соңгы вакытларда Столбище районы колхозчылары инициативасы буенча башланган гүзәл хәрәкәт, Зур Ферганә каналы төзелеше тәҗрибәсен республикабызның юллар төзелешенә күчерү хәрәкәте, бу мактаулы һәм җаваплы бурычны намус белән үтәү ышанычын ныгыта.

Турыдан-туры әйтергә кирәк: Казан—Чистай—Бөгелмә трактын тоташ төзек итеп төзү турында Столбище районы колхозчыларының мөраҗәгате массаның зур кызыксынуын тудырды. Бу чакыруга Столбище, Лаиш, Чистай, Кызыл Армия, Әлмәт һәм башка шундый районнарның йөзләрчә колхозлары практик эш белән җавап бирәләр. Бу районнарның партия, совет һәм комсомол оешмалары соңгы вакытларда да юл төзелешенә игтибарны күп тапкырлар көчәйттеләр. Юл төзелешенә практик ярдәм күрсәтү буенча ВКП(б) райкомнары каршында махсус комиссияләр оештырылып, эшкә башладылар. Бу комиссияләрнең эшләре белән турыдан-туры ВКП(б) райкомнарының икенче секретарьлары җитәкчелек итәләр. Комсомол оешмалары үзләренең иң яхшы кешеләрен юллар төзелешенә беркетәләр. Йөзләрчә комсомолецлар хәзер юл төзү бригадаларына җитәкчелек итәләр. Политик-тәрбия эшләрен оештыручы агитаторлар булып эшлиләр.

Дөрес, бу әле башлангыч адымнар гына. Масса активлыгын тагын да үстерү, аңа көндәлек җитәкчелек итү өлкәсендә эшлисе эшләр күп әле. Моны без бер генә минутка да хәтердән чыгармыйбыз. Алда торган бурычларны үз вактында намус белән үтәү өчен барлык игтибарыбызны туплыйбыз.

Столбище районы колхозчылары инициативасы нигезендә, Питрәч районының „Марс № 2“ артеле колхозчылары Казан—Алабуга—Минзәлә трактын төзекләндерү мәсьәләсен күтәрделәр. Билгеле булганча, югарыда күрсәтелеп үткән трактлар үз эчләренә тимер юл челтәре үтмәгән ерак районнарны алалар. Бу районнарны республикабызның башкаласы белән тоташтыралар. Бу трактларны якын арада тулы тәртипкә китерү республикабызның халык хуҗалыгының тагын да кызуырак темп белән үсүен тәэмин итә.

Хәзер без, юл төзелеше работниклары, алдынгы колхозчылар белән берлектә, төп игтибарны төзү материалларын эш объектларына ташуны якын арада тәгәлләү бурычын үтәүгә юнәлттек. Бу өлкәдә соңгы вакытларда сизелерлек борылыш күренә. Мәсәлән, Чкаловский трактында Столбище районы колхозчылары мөраҗәгатенә кадәр һәр ун көн саен бары тик 700—800 кубометр төзү материаллары ташылган булса, соңгы декадада бу сан 1.300—1.400 кубометрга артты. Ә февраль аенда бу эш тагын да көчәя бара. Столбище, Кызыл Армия районнарында юл төзелешендә һәр көнне 400—500 ат һәм 600—700 кеше эшли. Мондый күтәренкелек моңа кадәр күренгәне юк иде әле.

Һәрбер колхозда диярлек, юл төзелеше буенча даими бригадалар төзелә. Чистай шәһәрендә бу эшкә кайбер промышленность предприятиеләре дә кушылдылар. Бу предприятиеләрнең башлангычы Казан шәһәрендәге предприятиеләрне дә, бигрәк тә төзекләндерелә торган трактлар белән турыдан-туры бәйләнешләре булган Автоуправление җитәкчеләрен, Лаиш, Алексеевский заводлары һәм Вахитов исемендәге жиркомбинат кебек предприятиеләрне кузгатырга тиеш.

337 километрга сузылган Казан—Чистай—Бөгелмә трактында быел нинди эшләр башкарылачак соң?

Чкаловский трактында булган кызу хәрәкәт (җәй көннәрендә һәр көнне 500—600 автомашина үтә) юлларның нык булуын таләп итә. Шуңа күрә дә трактның хәзергә төзек булмаган 80 нән артык километрына быел без җидди реконструкция үткәрәбез. Шуның 22 километрына кара шоссе һәм чуер таш түшәләчәк. Ә калган өлешенә грави түшәләчәк. Бу төзелешне без тизләтелгән методлар белән башкарачакбыз.

Трактта төзү материаллары байлыгы гаять зур. Һәм алар төзелеш объектларына бик якыннар да. Бу исә безнең эшебезне җиңеләйтүгә зур ярдәм итә.

Моңардан тыш Чкаловский трактында культура төзелешләренә дә зур гына игтибар бирелә. Мәсәлән, Кама елгасы янындагы Шуран авылында автомашиналар өчен заправка пункты һәм ремонт базасы, Чистай белән Бөгелмә арасында пассажирларга ял итү өчен махсус павильоннар төзибез. Тракт буенча 12 мең данәдән артык агач утыртылачак һәм башкалар.

Алда торган бу эшләрне билгеләнгән срокта үтәп чыгу өчен төзелештә һәр көн 4.000 кеше һәм 2.000 ат эшләргә тиеш. Әһәмиятле төзелеш квалификацияле кадрлар булдыруны да сорый. Шунлыктан, без ЧТЗ тракторларында, грейдер машиналарында һәм беккер көрәкләрендә эшләү өчен квалификацияле кадрлар хәзерләү буенча Чистай шәһәрендә курслар оештырабыз. Бу курсларда укуга хатын-кызларны күбрәк тарту бурычын куйдык.

Трактны төзекләндерү эшләре нигездә уңыш җыю кампаниясе башланганчы тәгәлләнергә тиеш. Уңыш җыю кампаниясе вактында тик ярдәмче эшләр генә башкарылачак. Алда торган бу мактаулы һәм җаваплы бурычны үтәү өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Юллар төзү идарәсендә һәм шулай ук участкыларда да инженер-техник работниклар җитәрлек. Юллар төзү идарәсе 3 инженерны һәм берничә техникны Чкаловский трактында эшләргә билгеләде. Инженер Саянин һәм Курбатов иптәшләр төзелештә эшләү теләген белдерделәр.

Шик юк, Чкаловский трактын масса активлыгына нык таянган хәлдә, бердәм көч белән тулай төзек автомагистраль итәрбез. Юллар төзелеше буенча еллык планны срогында үтәү орденлы республикабызның XX еллык юбилеенә лаеклы бүләгебез булыр.

И. Арулин.

Татарстан Совнаркомы янындагы юллар төзү идарәсенең баш инженеры.

Чит илләрдә

БАЛКАН АНТАНТАСЫ СЕССИЯСЕНДӘ

СОФИЯ, 4 февраль. (ТАСС). Белградтан хәбәр итүләренә караганда, Балкан Антантасы сессиясендә председателлек итүче—Румыниянең чит ил эшләре министре Гафенку, пактта катнашучыларның теләкләре нигезендә пактның тагы 7 елга озайтылачагын белдергән.

Журналистлар даирәләрендә, бу карар, ихтимал, хәзерге шартларда Балкан Антантасында мөмкин булган барлык карарлардан иң ачык һәм әһәмиятле карар булыр дип күрсәтәләр. Англия—Франция хәрби блогының төп планы—Балкан илләрен Германиягә каршы юнәлдерелгән сугыш авантюрасына турыдан-туры тарту планы бик тиз җимерелгәнлектән, Төркия вәкиленең „Балкан оборона союзы"н төзү планы такдим иткәнлеге күрсәтелә. Ләкин асылда Англия—Франция блогының төп планы вариантларыннан берсе булган бу планны да яклаучы булмады. Шул уңай белән сессия ачыласы көн алдыннан Төркиянең Англия—Франция блогы белән Германия арасындагы сугышта нейтраль түгеллеге, бәлки сугышта гына катнашмавы турында Төркиянең чит ил эшләре министре Сараҗоглы тарафыннан ясалган белдерү нак менә Англия—франция хәрби блогының төп планы җимерелә калган хәлдә икенче вариант күтәрү өчен шарт тудыру теләге белән эшләнгән дип аеруча күрсәтелә.

Сессиядә катнашучылар арасында хәл ителә алмаслык каршылыклар барлыкны күрсәтеп, журналистлар Сараҗоглының югарыда күрсәтелгән белдерүенә Европадагы сугышта Югославиянең һәм Балкан Антантасының тулы нейтралитет сакларга тиешлеге турында Югославия чит ил эшләре министре Марковичның белдерүен капма-каршы итеп куялар. Болгария белән Румыния арасындагы мөнәсәбәтләр мәсьәләсенә сессия кулуарларында зур игтибар бирәләр. Добруджины автономияле дип иглан итү юлы белән Болгарияне „канәгатьләндерү" буенча сессиядә такдим ителгән проект Румыния тарафыннан ныклы отпорга очрады дип раслыйлар.

Болгариянең „Зора" газетасының махсус хәбәрчесе Белградтан: „Румыниянең үз чикләренең бөтенлеген сакларга карар биргәнлеген күздә тотып, Балкан Антантасы карарларының хәзерге хәлдә һичбер төрле үзгәрешләр китереп чыгармаячагы көтелә" дип хәбәр итә.

Хәбардар даирәләрдә, Балкан дәүләтләрен Германия белән экономик элемтәләрдән баш тартырга мәҗбүр итәргә Англия—франция блогының маташуларыннан бер нәрсә чыкмады һәм чыкмас дип раслыйлар. Болгариянең „Заря" газетасы, „Көнбатышка ориентация тота торган маглүм даирәләрнең Балкан Антантасы пактына үзгәрешләр кертергә тырышуларына карамастан" бу тырышулардан бер нәрсә дә чыкмас, дип яза. Шулай итеп, көтелгәнчә, Балкан Антантасы сессиянең беренче утырышлары ук пактта катнашучылар арасында гаять тирән һәм хәл ителмәслек каршылыклар барлыкны ачтылар. Шуңа да карамастан, өченче утырыштан соң иглан ителгән рәсми белдерүдә болай диелә:

„Балкан илләренең 4 министре кичәге утырышта күтәрелгән мәсьәләләрне тикшерүне дәвам иттерделәр. Бүген сессиядә тикшерелгән политик һәм экономик мәсьәләләрдә аларның карашлары бердәм икәнлеге күренде".

Балкан Антантасы сессиясенең ябылуы

СОФИЯ, 4 февраль. (ТАСС). Бүген Балкан Антантасының даими советы сессиясе ябылды.

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

БЕРЛИН, 3 февраль. (ТАСС). Информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Фишбахтан көньякта каршы якның разведка отряды германнарның мина кырына эләккән һәм, югалтулар биреп, шунда ук чигенгән.

ПАРИЖ, 4 февраль. (ТАСС). Кичә Рейн елгасы буендагы һәм югары Эльзастагы фронтта мылтыктан атышу булганлыкны хәбәр итәләр. Вогезының көнбатыш ягында патрульләр хәрәкәте булган.

БРЮССЕЛЬ, 4 февраль. (ТАСС). Франциянең 2 нче февральдә чыгарылган белдерүенә карата Бельгиянең „Суар" газетасы тарафыннан иглан ителгән аңлатмаларда түбәндәгечә күрсәтелә: „Сугыш башланган вакыттан бирле диярлек Рейн буендагы участкыда булган тулы тынычлык хәзер активлык белән һәм кайбер көннәрдә бик көчле активлык белән алмашынды. Анда артиллерия һәм пулемет атышуы бара. Дошманнар арасындагы дистанция шул кадәр якын ки, хәтта каршы яктан кешеләрнең тавышлары ишетелә. Ныгытмалар беренче империалистик сугышның траншеяларын хәтерләтәләр".

БЕРЛИН, 4 февраль. (ТАСС). Информация бюросы, Германия самолетларының кичә төньяк диңгез өстендә разведка очышлары вактында Англиянең хәрби корабларына һәм кораллы сәүдә пароходларына атака ясаганлыкларын хәбәр итә. Дошманның зенит орудиеләреннән һәм истребительләреннән көчле ут ачылуына карамастан, Англиянең бер траулеры, 4 сакчылык карабы һәм 9 сәүдә пароходы батырылган, Бик күп пароходлар шактый дәрәҗәдә зарарланганнар. Германиянең 3 самолеты кайтмаган.

БЕРЛИН, 3 февраль. (ТАСС). Информация бюросы Стокһольмнан, сугыш башланганнан бирле Швеция пароходчылыгының барлыгы 60.084 тонна авырлыгында 31 пароход югалтканлыгын хәбәр итә. Шуның белән бергә Швециянең 205 морягы һәлак булган.

РӘСЕМДӘ: „И. Сталин" һәм „Г. Седов" бозваткычлары Кальский заливтан Мурманскига баралар.
Ә. Ханкина фотосы. (ТАСС фото-клишесе).

МӘРЬЯМ РАХМАНКУЛОВА КОНЦЕРТЫ

Татарстанның атказанган артисткасы Мәрьям Рахманкулованың шушы көннәрдә булып узган концерты турында рецензия язу дигән сүз—күп санлы тыңлаучылар исеменнән җырчыга рәхмәт тойгысы белдерү дигән сүз ул. Чынлап та, киң диапазонлы һәм югары культуралы безнең җырчыларыбызның сафы үскәннән-үсә бара һәм күренекле татар җырчыларыннан берсе булган Мәрьям Рахманкулова әнә шул сафта почетлы урынны алып тора.

Мәрьям Рахманкулова халык җырларын үтәгән чакта шул чаклы нечкә һәм художество сизгерлеге күрсәтә ки, аның бу өлкәдә үзен таныта алуы, һич шиксез, бик табигый һәм шатлыклы бер хәл булып тора.

Мәрьям Рахманкулова үзенең зур талантлы җырчы булуын татар совет композиторларының ялгыз җыр өчен язган әсәрләрен башкарган чакта да күрсәтә алды.

Катлаулы һәм читен ике өлкәдә—камера сәнгате һәм халык җыры өлкәләрендә—югары мастерлык күрсәтә алу, шуның янына тагын Татар Дәүләт Опера театрының алдынгы солисткаларыннан берсе булу, безнең карашыбызча, Рахманкулованың эзләнүчән талантын канәгатьләндерү өчен җитәрлек нәрсәләр, ләкин, соңгы концерты аның югарыда искә алынган өлкәләр белән генә чикләнеп калырга теләмәгәнлеген, балалар өчен булган музыкаль-вокаль жанр буенча да эзләнгәнлеген күрсәтте.

Мәрьям Рахманкулова үзенең көчле талантын, бигрәк тә халык җырларыннан „Агыйдел" (музыкасы композитор Мозаффаров тарафыннан эшләнгән), „Авыл җыры" (Ключарев музыкасы), башкырт халык җыры „Баек" (Виноградов музыкасы) һәм „Башмаклар" җырларын үтәгән чакта күрсәтте. Аның бу номерлары тыңлаучыларның күңелендә бик озак сакланыр дип ышанып әйтергә була. Шулай ук композитор Җәүдәт Фәйзи тарафыннан язылган „Карак песи" һәм „Әтәч" җырларын да шулар рәтенә кертергә кирәк.

Тыңлаучылар Мәрьям Рахманкулованың талантына югары бәя биреп, аның иҗадындагы төрлелекне, капма-каршы образларны дөрес чагылдыра белүне алкышлап каршы алдылар.

Мәрьям Рахманкулова үзенең зур һәм матур иҗадының чәчәк ату чорына керде. Без аңа киләчәк эшенә яңа уңышлар теләп калабыз. Шулай ук концертның уңышлы үтүенә күп кенә ярдәм иткән икенче иптәшләргә дә—пианистка Л. Голяко, скрипач Я. Шейн һәм виолончельдә уйнаучы Л. Варшавский иптәшләргә дә уңыш теләп калабыз.

ТАССР ның атказанган сәнгат эшлеклесе профессор *Литинский*.

БАЛКАН АНТАНТАСЫ СЕССИЯСЕ ТУРЫНДА ЧИТ ИЛ МАТБУГАТЫ

АНГЛИЯ

ЛОНДОН, 4 февраль. (ТАСС). Англия матбугаты Балкан Антантасы сессиясе ачылыр алдыннан Антантада катнашучыларны турыдан-туры куркыту методын күп тапкырлар кулланды. Мәсәлән, „Дейли телеграф энд Морнинг пост" соңгы 4 көн буена Югославия чигендә, имештер, Германиянең 3 дивизиясе тупланганлык турында Париждан алынган хәбәрне сенсацияле хәбәр итеп басып чыгарды.

„Ньюс кроникл" күренекле урында: „Германия тарафыннан булган куркыныч уңае белән Европаның көньяк-көнбатышындагы илләр өчен куркынычлы сәгат килеп җитте" дип язды. Шуның белән бергә мәкаләнең авторы түбәндәге характерлы „нәтиҗә" гә килә: яки Балкан Антантасы илләре бердәм блокка берләшергә тиешләр, яки Англия һәм Франция бу илләргә ярдәмгә килә алмаганлыктан бу илләрнең аерым-аерым тар-мар ителүләре мөмкин. Бер үк вакытта „Дейли телеграф энд Морнинг пост" газетасы Германиягә каршы экономик фронт төзергә чакырды.

Ләкин, үзенең планнарын үтәүнең кыенлыгына ышанганлыктан булса кирәк, Англия матбугаты соңгы көннәрдә өметсезләнү һәм борчылу билгеләре күрсәтә. „Таймс" газетасының хәбәрчесе ачыктан-ачык борчылу белән болай дип яза: „Бөек державаларга һәм бигрәк тә сугышучы тарафларга карата Балкан Антантасының коллектив политикасы турында сүз барганда һәр вакыт нейтралитет турындагы томанлы сөйләшүләр белән котылып калырга тырышалар. Бу сөйләшүләр гадәттә тынычлыкны саклау кирәклегенә карата оятсыз төстә сылтау ясау белән бара".

ГЕРМАНИЯ

БЕРЛИН, 4 февраль. (ТАСС). Германия матбугаты Балкан Антантасы сессиясенә шактый зур игтибар бирә. Сессия ачылудан элек үк „Фелькишер беобахтер", „Дейче альгемейне цейтунг" һәм башка газеталар Балкандагы хәлгә һәм көньяк-көнчыгыш Европа илләре белән Германиянең мөнәсәбәтләренә багышланган мәкаләләр басып чыгардылар. „Фелькишер беобахтер" һәм башка газеталар Белградтагы конференциянең Балканда тынычлыкны саклауны яклаячагына һәм Балкан илләрен көнбатыш державаларның сугышка тартырга маташуларына отпор бирәчәгенә ышаныч белдерәләр.

„Фелькишер беобахтер" болай дип яза: „Германия Белград сессиясе белән табигый рәвештә кызыксына. Ул көньяк-көнчыгыш Европа илләренең Германиягә каршы файдаланылмауларын тели".

„Дейче дипломатиш-политише корреспонденц" газетасы Балкан Антантасы сессиясенә багышланган мәкаләсендә болай дип яза: „Тынычлык һәм солых Лондон һәм Париж интересларына каршы килә. Англиянең һәм Франциянең максаты—солыхны һәм тынычлыкны юкка чыгару. Балкан Антантасында катнашучыларның берсе—Европа сугышы башланганнан соң көнбатыш державаларның союзнигы булып әверелгән ил дә һич шиксез шулар исәбенә керә. Бу факт һич шиксез сессиянең игтибарын үзенә тартырга тиеш. Балканга каршы Германия планнары турындагы, көньяк-көнчыгышка һөҗүм хәзерләү өчен имештер, Германия гаскәрләрен туплау турындагы һәр төрле әкиятләр Германиянең Балканда тынычлык сакларга теләвенә пычрак ташлыйлар. Көньяк-көнчыгыш халыклары моның дөрес түгеллеген беләләр. Европаның көньяк-көнчыгышы үз халыклары интересларыннан чыгып эш итәр".

БОЛГАРИЯ

СОФИЯ, 4 февраль. (ТАСС). Болгария газеталары Балкан Антантасы сессиясендәге эшнең барышы белән нык кызыксыналар. „Слово" газетасының Белград хәбәрчесе, сессиядә тикшерелгән мәсьәләләрнең берсе Болгария мәсьәләсе булды, дип яза.

Редакция исеменнән язылган „Балкан Антантасы һәм чит йогынтылар" дигән мәкаләдә „Слово" газетасы, Англия—Франция блогының политикасы турында болай дип яза: „Бүген Балкан дәүләтләре үз тирәләренә куелган җәтмәне бик ачык күрәләр. Аларның башкалар өчен уттан борчак чүпләргә теләмәүләре бик мактаулы".

Газета болай дип яза:

„Балканда канәгать һәм канәгать булмаган дәүләтләр булганда нинди булса да бергәләп хәрәкәт итү мөмкинмени? Белградта боларның барсын да аңларлармы икән? Авторитетлы кешеләрнең белдерүләренә һәм конференция тирәсендә тудырылган атмосферага карап безнең оптимист булырга нигезебез юк".

АКШ

НЬЮ-ЙОРК, 4 февраль. (ТАСС). Ассошиэйтед пресс агентлыгы Белградтан, аерым илләрнең интереслары арасындагы каршылыклар Балкан Антантасын киңәйтүдә киртә тудыралар дип хәбәр итә. Румыния, Төркия, Югославия һәм Греция вәкилләре Балкан илләре конференциясендә, бу конференция нинди булса да карар кабул итә алырлык түгел дип раслыйлар. Балкан илләренең бердәмлеге урнына, бу илләрнең һәр кайсы бөек державаларның ярдәме белән үзенең территориаль кагылгысызлыгын тәэмин итәргә маташа.

Кытайда сугыш хәрәкәтләре

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Наньнин—Циньчжоу (Гуанси провинциясе) арасындагы шоссе юлында кытайлар японнарны берничә пункттан кысрыклап чыгардылар.

Наньниннан 120 километр төньяк-көнчыгышта кытай авиациясе японнарның самолетын бәреп төшерде.

Кантоннан көнбатышта японнар отряды Самшуй секторында кытайларның позицияләренә атака ясады. 2 сәгатьлек сугыштан соң японнар чигендерелде. Сугыш кырында аларның үтерелгән һәм яраланган 100 гә якын кешеләре калды.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Японнарның Баотоуга (Суйюань провинциясе) һөҗүм итә торган гаскәрләре көньяк-көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш юнәлешләрендә кытай гаскәрләренең каты каршылык күрсәтүләренә очрыйлар. Япон гаскәрләренең Баотоу—Уюань тракты буйлап һөҗүм итә торган колоннасы Улашань таулары районында кытайлар тарафыннан туктатылды. Японнар зур югалтулар бирделәр.

Японнарның биредә операцияләр алып бара торган гаскәрләрендә 15 мең кеше санала.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Чжэцзян провинциясендә Цяньтан елгасының көньяк яры буенда сугышлар яңадан башланды.

Үзәк Кытайның башка фронтларында әһәмиятле үзгәрешләр юк.

„Шяньчжоужибао" газетасының хәбәр итүенә караганда, японнарның Кантонда урнашкан гаскәри часте 27 нче январьда фронтка бару турындагы приказны үтәүдән баш тарткан. Властьлар солдатларны коралсызландырырга маташканнар. Ләкин солдатлар кораллы каршылык күрсәткәннәр. Солдатлар белән жандармнар арасында булган бәрелеш нәтиҗәсендә һәр ике яктан 40 ка якын кеше үтерелгән һәм яраланган. Восстание бастырылган.

ПИОНЕРЛАР ҺӘМ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНЫҢ ХӘРБИ ЯРЫШЛАРЫ

ВЛКСМ Үзәк Комитеты, профсоюзларның Бөтенсоюз Үзәк Советы, Осоавиахим Үзәк Советы һәм Кызыл Хач Җәмгыятенең Башкарма Комитеты үткән елдагы кебек быел да пионерларның һәм укучы балаларның хәрби - физкультура ярышларын үткәрергә карар бирделәр.

Ярышларда урта мәктәпләрнең 5, 6, 7, 8, 9 һәм 10 нчы классларь катнашалар. Ярышлар ике группага бүленеп үткәреләчәк. Беренче группада ату, ПВХО, элемтә, ГСО һәм хәрби топография буенча, икенче группада бу төрләр өстенә тагын граната ыргыту буенча ярышлар булачак.

Хәзер барлык районнарда ярышларны оештыру комитетлары төзелә. Ләкин Бөгелмә, Ютазы, Тельман, Баулы, Беренче Май һәм башка кайбер районнарда бу комитетлар әле тиешенчә эшләмиләр. Республика күләмендә төзелгән оештыру комитеты да (председателе ВЛКСМ Өлкә Комитеты секретаре Ханова) урыннардагы оештыру комитетларына җитәкчелек итми.

1940 нчы елда үткәреләчәк оборона ярышлары пионерлар һәм мәктәп балалары арасында оборона эшенең торышына җәмагать смотры булачак. Яш патриотлар ярышларда үзләренең хәрби белемне ничек үзләштерүләрен һәм бу өлкәдәге мастерлыкларын күрсәтәчәкләр. Совет балалары үзләренең бу ярышларында Ватанга, большевиклар партиясенә һәм бөек Сталинга чын күңелдән бирелгән булуларын тагын бер тапкыр күрсәтәчәкләр. *Бикеев.*

„КАЗАНДА ЛЕНИН БУЛГАН УРЫННАР"

Союзкинохрониканың Казан студиясе „Казанда Ленин булган урыннар" дигән кино - очерк хәзерли. Журнал бөтенсоюз экраны өчен тавышлы итеп эшләнә.

Кино очеркта Ульяновлар семьясенең Казанда торган йортлары, Казанда Ленин музей-йорты, Казан Дәүләт Университеты, Кокушкино (хәзерге Ленино) авылында Ленин музей-йорты һәм башка урыннар күрсәтелә.

Мөхәммәт Юсупов

Шушы елның 3 нче февралендә атаклы музыкант - скрипач Мөхәммәт Гали улы Юсупов үлде. Ул 1900 нче елда Казан шәһәрендә, хезмәткәр семьясендә туган. Киң хезмәт ияләре массасы аның скрипкада татар халык көйләрен искиткеч матур итеп, мастерларча башкаруын әле күптән түгел генә, Казан музыка фольклоры кабинеты тарафыннан оештырылган радио концертта, 28 нче январьда гына ишеткән иде. Ул хезмәт иясе халкының яраткан музыкант-скрипачларыннан берсе иде.

1914 нче елларда Мөхәммәт Юсупов, музыкант-скрипач буларак, Сайяр труппасының спектакльләренә катнаша башлый. 1917 нче елдан профессионал музыкант була һәм шушы көнгә кадәр Татар Дәүләт Академия театрында эшли.

Аның таланты безнең илебездә—Совет Ватанында чәчәк атты. Ул йөзләгән халык көйләрен күңеленнән белү һәм аларны дөрес итеп, искиткеч матур итеп башкару дәрәҗәсенә ирешә. Һәм ул үзенең бөтен күңлен, тормышын татар хезмәт ияләренең музыка культурасын өйрәнү һәм үстерү эшенә багышлады. Фольклор кабинетына да татар халкының шактый гына гүзәл көйләрен тапшырды.

Хуш, кадерле дус һәм иптәш Юсупов.

Халык сине һәр вакыт мәхәббәт белән искә алыр.

ТАССР ның атказанган сәнгат эшлеклеләре: *А. Ключарев, Н. Җиһанов, Т. Гыйззәт, С. Сәйдәшев.*

ТАССР ның атказанган артистлары: *Х. Сәлимҗанов, М. Рахманкулова* һәм иптәшләреннән: *М. Садри, В. Виноградов, М. Мозаффаров, Җ. Фәйзи, М. Яушев, Блинов, И. Юзеев, Хәлимов.*

ЯШ ШАХМАТЧЫЛАР ЯРЫШЫ

Сарман урта мәктәбе укучы балаларының шахмат буенча ярышлары үткәрелде. Ярышларда барлыгы 12 укучы катнашты.

Укучы Ф. Ибраһимов мөмкин булган 11 очкодан 11 очко җыеп беренче, М. Ибраһимов 10 очко җыеп икенче урыннарны алдылар.

Шахмат турниры укучылар арасында зур кызыксыну тудырды. *Әкмәл Камалов.*

Студентлар һәм фәнни работниклар чаңгы спорты белән шөгылләнәләр

Чаңгы спорты Казан Дәүләт Университеты студентларының һәм фәнни работникларының иң яраткан спортларыннан берсе. Университетның чаңгычылар секциясе яхшы эшли. Секция тарафыннан оештырылган түгәрәкләрдә 100 дән артык студент һәм фәнни работник тәртипле рәвештә чаңгы спортын үзләштерәләр.

Күптән түгел Ленино авылына һәм Займищегә чаңгы походлары үткәрелде. Бу походларда чаңгычылар актив катнаштылар. Каникул көннәрендә шәһәр тирәсенә чаңгыларда прогулкалар үткәрелә.

Физика-математика факультетының ассистенты иптәш Кап чаңгы спорты белән өзлексез рәвештә шөгылләнә. Ул: „Чаңгыда йөрү мине физик яктан чыныктыра һәм минем фәнни эш алып баруыма зур ярдәм итә" ди. География факультетының 5 нче курс студенткасы иптәш Архангельская да университетка кергән елдан башлап чаңгы спорты белән шөгылләнә. *Д. И.*

БЕЛДЕРҮЛӘР

7 нче февраль, кич 7 сәгаттә, Казан Дәүләт университетының актовый залында Молотов районы өчен лекция үткәрелә. Тема: „Кешеләрнең аңнарында капитализм калдыкларын бетерү". Лектор иптәш Степанов.

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитетының оештыру-инструкторлык бүлеге түбәндә фамилияләре күрсәтелгәннәрнең 19 нчы бүлмәгә эш сәгатьләрендә килүләрен сорый: Ситдик Нурый улы Нуриев, Гали Зәйнуллин, Василий Ильич Абрамов, Ольга Яковлевна Сорокина, Феврония Васильевна Васильева һәм Егор Тимофеевич Тимофеев.

Җаваплы редактор Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

„АВТОУЧТЕКСТИЛ"
КАЗАН АВТОМӘКТӘБЕ
производстводан аерып һәм аермыйча укытып III нче класс шоферлар хәзерләү курсларына
— УКУЧЫЛАР АЛА —
Уку сроклары: производстводан аерылып уку группасында—2 ай ярым, ә производстводан аерылмыйча уку группасында—5 ай.
Укулар шушы ел 10 нчы февральдән башлана. Курсларда укыту өчен түләү алынмый.
Курсларга 18 дә һәм аннан югары яшьтәге кешеләр 6 класс күләмендәге белем белән алыналар. Командировка соралмый.
Кызыл Армия бистәсе, Кече Москва урамы, 16, 32 нче мәктәп.
Гаризалар гомуми ял көннәреннән башка һәр көн иртән 9 сәгаттән кич 7 гә кадәр алына. 1—1

Барлык оешмалар, учреждениеләр һәм предприятиеләр игтибарына.
ГОРНАРХОЗУЧЕТ
—Кремльгә күчте—
(4 нче подъезд, ТУНХУ бинасы). Телефон 42—81. 223—1

Казан шәһәре Бауман Райжилуправлениесенең приказы нигезендә, Бауман Райжилуправлениесенә караган—
2 нче ЙОРТ УПРАВЛЕНИЕСЕ
шушы ел 1 нче февральдән
бетерелде
Шул йорт управлениесенә карата булган дәгъвалар 20 нче февральгә кадәр алына.
Күрсәтелгән сроктан соң бирелгән дәгъвалар каралмаячак. Чернышевский урамы, 7.
225—1 ЛИКВИДКОМ.

„СОЮЗЗАГОТШЕРСТЬ" НЫҢ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКА
— КОНТОРАСЫ —
Ухтомский урамындагы 5-16 нчы номерлы йортка
КҮЧТЕ
Телефоннар: 21—78 һәм 7—73. 227—1

СНАБЭЛЕКТРО ГОРЬКИЙ КОНТОРАСЫНЫҢ КАЗАН БҮЛЕГЕ
Чернышевский урамындагы 9 нчы йорттан Булакның уң ягы урамындагы 29 нчы йортка
КҮЧТЕ
Хезмәт күрсәтү операцияләре буенча сөйләшү өчен килү һәм корреспонденцияләр җибәрү өчен шул яңа адресның истә тотылуы сорала. 202—1

Казан Дәүләт Медицина институтының тире авырулары клиникасындагы
косметика һәм гигиена
КАБИНЕТЫНДА
(Толстой урамы, 4, телефон 33—79)
сыткыларны, бетчәләрне, сипкелләрне, миң, сөял кебек тиредәге төрле кимчелекләрне дәвалау, биткә массаж ясау, тирене тәрбияләү, чәчне дәвалау һәм доцентлар тарафыннан консультацияләр бирү эшләре алып барыла.
Кабул итү—түләүле, гомуми ял көннәреннән башка һәр көн көндез 4 сәгаттән кич 7 гә кадәр. 2427—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
6 нчы февральдә көндез 12 сәгаттә
КҮЗЛӘР (талон 109)
кич КЫЮ КЫЗЛАР (талон 110).
7 һәм 8 нче февральдә
БУЛАК АРТЫ „РЕСПУБЛИКАСЫ"
Талоннар: 111 һәм 112.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
6 нчы февральдә көндез
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
кич МАСКАРАД
Талоннар: көндез 19 һәм кич 94.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
БҮГЕН ҺӘМ ҺӘР КӨН
Москва 4 нче труппасының
— соңгы гастрольләре —
ПОПУЛЯР КОМИК, ҺӘР ТӨРЛЕ ХАЙВАННАРНЫ ӨЙРӘТҮЧЕ,
РСФСР ның атказанган артисты, орденлы
М. ЗОЛЛО үзенең антропозоологик — труппасы белән —
6 нчы февральдә көндез 1 сәгаттә
М. ЗОЛЛО
катнашы белән зур цирк уены.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„УНИОН" 11, 1-20, 3-40, 6, 8-20, 10-30 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	ЦИРК
„Колхозник" 6, 8 һәм 10 да.	БӨЕК БҮЛӘК
„ЧАТКЫ" 6, 8 һәм 10 да.	ТАЙГА ЕРАКЛЫКЛАРЫНДА
„ПИОНЕР" 10, 11-20, 1, 2, 3-30, 6, 8 һәм 10 да.	Көндез ФЕДЬКА Кич ТРАКТОРЧЫЛАР Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яшьтәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ" 4, 6, 8, 10 да.	БӨЕК ГРАЖДАНИН (2 нче сериясе)
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ